# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МӘТӘСКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**Унтугызынчы утырыш дуртенче чакырылыш**

**16 декабрь 2022ел** **№ 76** **Олы Мәтәскә авылы**

Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советының 18.05. 2018 ел № 77 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезләмә хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлек башлыкларын, муниципаль берәмлек башлыклары урынбасарларын, депутатларны, сайланулы җирле үзидарә органнары әгъзаларын, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советы карар итте,

1. Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советының 18.05. 2018 ел № 77 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезләмә хакында» ( 20.09.2018ел. №82; 09.10.2018ел. №90; 20.12.2018ел. № 98; 18.05.2019ел. № 111; 29.08.2019ел. № 114; 24.10.2022ел № 73) карарлар редакциясендә) (алга таба текст буенча - карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«1. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 12688 сум итеп расларга.».

1.2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларның һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең 11.5 пунктын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«11.5 Муниципаль хезмәткәргә хезмәт хакының 18 процентыннан артмаган күләмдә айлык акчалата бүләкләү билгеләнә.».

1.3. Карарның 2 номерлы кушымтасын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Теләче
муниципаль районы Олы Мәтәскә
авыл җирлеге Советының 18.05.2018
ел № 77 2 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыгын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын айлык акчалата бүләкләү күләме

| Вазыйфа исемнәре | Айлык акчалата түләү, сум |
|---|---|
| | 12 төркем |
| 1 | 2 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 17 390,0 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары | 12689,0 |

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы
Олы Мәтәскә авыл җирлеге
башлыгы М.А.Валиуллин